Миңа биш яшьләр тирәсе. Өйдә тып- тын. Тәмле итеп кыздырылган бәрәңге исе борыннарны кытыклый.Беләм инде: картәтием мин торуга бәрәңге кыздыра.  Һәм бу һәр көнне шулай кабатлана. Кече якка чыга торган ишекне ябып куйса да( мине уятмыйм диптер инде) , мин аның һәр адымын сизеп ятам. Менә хәзер ул минем янга килеп: “ Эльнара кызым, торасыңмы инде?”, - дип йомшак кына эндәшәчәк һәм без икәүләп аның белән кетердәп торган бәрәңге белән чәй эчәчәкбез.

Аннан ул капка төбендәге эскәмиягә чыгып утырачак. Иртәнге кояшка, өйгә терәлеп үскән  карт ак каенның яфраклары шыбырдашуына, кошлар сайравына сокланып, моңсуланып тын гына утырачак. Моңсулана шул картәтием, чөнки картыебыз( бездә картәнине шулай диләр) , көтмәгәндә генә вафат булып, безне дә, картәтиемне дә ятим итте.

Ә миндә моңсулыкның эзе дә юк. Тик уйнавымны беләм. Кайвакыт картәтиемнең тезләренә менеп утырам да кысып- кысып кочаклыйм үзен. .Яратам, бик яратам шул мин аны.

Ә кайчакта без аның белән , сандыктан алып, иске альбомнарны карыйбыз. Менә бу фотодан яшь, баһадирларча гәүдәле картәтием карый, монда алар картыем белән бергә  төшкәннәр.Ә монысы туристик путевка белән Ригага баргач төшелгән. Сандык төбендә ак кулъяулыкка төрелгән орденнар мине бигрәк тә кызыктыра. Мин алар белән  уйнарга яратам. Картәтиемә сораулар бирә- бирә аптыратып бетерәм.

Ә ул  басудан алып кайткан кечкенә кәнфитләрнең ( “куян күчтәнәчләре”) тәмлелеге!

Бик дусбыз без аның белән. Ул берәр җиргә китсә, мин аның кайтуын түземсезләнеп көтәм. Ул күренү белән, каршысына йөгерәм , ул мине күтәреп алгач, үземнең хәбәрләремне сөйләргә тотынам.Ул елмаеп, баш кага – кага тыңлый. Төннәрен йоклый алмый ятсам, картәтинең җылы куенына кереп ятуым була- йоклап та китәм. Кайбер чакта, бигрәк тә гаиләбез белән кичен бергә җыелганда, ул гармунын ала һәм бию көйләре уйный. Без Элина апам белән идән уртасында тыпыр- тыпыр биибез. Картәти моңа балаларча куана һәм тагы да дәртләнебрәк уйный башлый.

Аннан әле ул ел саен клубта узган Яңа ел кичәсендә Кыш бабай була.

Болар – балачак хатирәсе. Картәтием беркайчан да үлмәс, мәңге безнең белән яшәр  кебек тоелса да, уйламаганда- көтмәгәндә  67 яшендә үлеп китте.

Минем өчен ул картәти, бары яраткан картәти генә иде. Балалыгым белән мин аның кем булуын аңлап та бетермәгәнмен.

Туган колхозы- Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы 22 партсъезд исемендщге хуҗалыкта  40 елдан артык  тракторчы былып эшләп, тырыш, намуслы хезмәте өчен “ Октябрь революциясе”, “ Ленин” ордены ,

“ Фидакарь хезмәт өчен” бронза медале белән бүләкләнгән картәтием- Зиннәтуллин Илдус Әдиятулла улы турында сөйләргә телим бу язмамда.

Картәтием – бик күпләр кебек сугыш чоры баласы. Әтисе Әдиятулланың һәлак булуы турында кара кәгазь килгәндә, аңа биш яшь ,сеңлеләренең берсенә-өч, икенчесенә-ике генә яшь була. Бик бәләкәй көе колхоз эшенә җигелергә туры килә аңа .Эшләмичә булмый. Хезмәт көненә әз булса да он бирелә. Эй, ул елларның авырлыгы... Өйдә еш кына ашарга бернәрсәбулмый. Икмәк күргәннәре юк. Җәйләрен какы, балтырган белән бераз тамак ялгарга була. Язларын басудан үткән елдан калган черек бәрәңге( кәлҗемә) таба алсаң, олы бәхет инде. Кышлар бик авыр.Үзәккә үтәрлек салкыннар, ачы буран. Ә өстә ямаулы кием, аякта чабата. Картәтиемнең бик якын туганы, Татар Мәнәвез авылында туып – үскән, гомерен балаларга белем бирүгә багышлаган Фәнә апаның “ Азатлык хакы” шигырен укыганда , картәти сөйләгәннәр искә төшә.

Сугыш чоры баласы мин,
Күңелкәем яралы,
Без кичергән михнәтләрнең
Эзе һаман бар әле.
Һәр өйнең түрендә ачлык
Хуҗа булды масаеп,
Кәлҗемә чокып , куллар да
Яргаланды караеп.
Әмма бирешмәдек, үтте
Давыллы , утлы яшен.
еңде җиргә әти каны,
Һәм минем түккән яшем.



1956 елда ул Бакалыга барып укып, тракторчы таныклыгы ала. Менә шуннан бирле, лаеклы ялга чыкканчы, ул трактордан төшми.

Ул сызган буразналарны бергә кушсаң, ничә чакрымнарга сузылыр иде микән?! Иртә яздан тырмада да, туфрак әзерләүдә дә, чәчүдә дә эшли. Көн үтсенгә беркайчан да йөрми. Бите- кулы мазутка буялып бетсә дә, мамык кебек күпереп торган кап-кара басуларга карап торып, үзенең дә күңеле рәхәтлек кичергәндер. Кышын бөтен авыл урамнарын кардан чистарту эше аңа тапшырылган. “Гади көрәк белән урамнарны ,грейдерлап куйгандай, тип-тигез итеп куя иде”,- дип хәтерли аны белгән кешеләр.

Яз көне, чәчүләр беткәч, авыл халкының бәрәңге бакчаларын сөрә. Һәр кеше күңеленнән генә: “Бакчамны Илдус сөрсә ярар иде”,- дип тели, чөнки ул ашыкмыйча гына, тип-тигез итеп сөрә, бер кәсе дә калмый.

Тракторчыга үткен күзле, югары ишетү сәләтенә ия, бик игътибарлы, чыдам, зирәк, көчле реакцияле , физик яктан нык булу сыйфатлары кирәк икән. Кышкы чатнама суыкларда төн уртасында, чылбырлы тракторларын кабызып, урманга чыгып киткән, тузанга батып, көннәр буе дыңгыр- дыңгыр килеп, басу сөргән картәтием һичшиксез шушы сыйфатларга ия булган. Көтелмәгән, куркыныч хәлләргә дә очрарга туры килгән аңа. Кышларын Агыйдел аша , боз туңгач, колхозга агач ташыйлар. Һәм берсендә картәтием алдыннан барган трактор боз астына төшеп китә. Ярый әле тракторчысы кырыйга сикереп өлгерә. Тракторны берничә көннән соң трослар белән тарттырып чыгаралар.

Үзе йөрткән ДТ-75 тракторын тере кешедәй күргән картатием. Тракторның тавышында чак кына үзгәреш сиздеме-хәзер төшеп караштыра, төзәтә. Менә бу басуның эшен бетереп, икенче басуга күчәргә кирәк. Бер көне-елны туйдыра торган вакыт бит. Җир ялкауларны яратмый. Ә үзенең кадерен белгәннәрдән мул уңышын кызганмый. Ләкин басу-кырларда кара икмәк салыр өчен арыш, ак ак күмәчләр пешерергә бодай, ботка пешерер өчен карабодай белән тары үстерер өчен, ай-һай, бик нык тырышарга, җиде кат тиреңне түгәргә туры килә. Әллә шулай игенченең кара тире тамганга, бик тәмле микән ул ипекәй?!

Әтием сөйләвенчә, алар этиләрен бәләкәй чакта юньләп күрмәгәннәр дә. Иртәләрен ул эшкә киткәндә, алар әле тәмле йокыда калган, ә ул эштән кайтканда, алар инде йоклаган булганнар.

Картәтиемнең хезмәте лаеклы бәяләнгән. Ул орден- медальләргә лаек булып, Мәскәүдә Бөтенсоюз халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә



катнашкан, туристик путевка белән Латвия, Белоруссиягә барып кайткан.

Ул гаиләсендә дә бәхетле булган. Картыем Әдибә белән яшьли кавышып , матур гаилә корып, биш балага гомер бүләк иткәннәр. Атадан күргән-ук юнган ,дигәндәй, аның уллары барысы да гармунда уйнарга өйрәнә, кызлары бик матур итеп җырлый. Өч улы да ил алдындагы бурычларын намус белән үтәп кайткан. Илфир абый белән Илшат абый

Әфганстанда хезмәт иткән. Кызганычка каршы, гармун телләренә басып, аны коштай сайратучы моңлы Илфир абыем гына, утлы Әфган юлларын, үтеп,тәненә бер ярчык тидермичә исән-сау кайтып та, тыныч тормышта һәлак була. Картәти- белән картыйның мәңге төзәлмәс ярасы булды абыем.

Картәтинең язмышы ил язмышыннан аелылгысыз. Икмәк фронтында барган алышта ул сынатмаган. Илебез үсеше өчен үзенең хезмәтен салган, йөрәк җылысын биргән. Боларны ул без -аның балалары, оныклары бәхетле, мул тормышта яшәсен өчен дә эшләгән.

Юксынамын сине, картәти. Һәр иртәдә: “Кызым, тор, бәрәңге пеште”,- дип эндәшерсең кебек. Басудагы тракторлар тавышын ишетү , шкаф башында ямансулап торган гармуныңны күрү сагынуымны тагы да көчәйтә.

Кеше китә- җыры кала ,диләр. Картәтиемнең - түккән һәрбер тамчы тирем бөртек булып шытсын дип, кара туфракка табынып яшәгән игенченең- гомере үзе матур бер җырга тиң түгелмени?!

Эльнара Зиннәтуллина,
Базытамак урта мәктәбенең
9 нчы сыйныф укучысы.